Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN

УНИВЕРСИТЕТ

№ 21 (34)

28 июнь 2012 ел

## • Ике авыз сүз

25 июнь көнне **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Утырышны уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов алып барды.

Көн тәртибенә куелган сорауларны карый башлаганчы, фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев Марат Арсланов җитәкчелегендәге математика һәм механика өлкәсендә эшли торган алдынгы фәнни мәктәпкә Россия Федерациясе Президенты грантын алу өчен таныклык тапшырды.

Алга таба кабул итү комиссиясе сәркатибе Сергей Ионенко быелгы кабул итү кампаниясенең торышы турында мәгълүмат җиткерде. 25 енә кадәр 815 гариза кабул ителгән (бюджетка – 605, контракт буенча – 210), күбесе электрон рәвештә тутырылган. Абитуриентларның саны БДИ сертификатларын алгач артыр дип көтелә. Шулай ук Сергей Ионенко документларны тапшыру сроклары һәм кабул итү имтиханнары тәртибе белән таныштырды.

Журналистика һәм социология факультеты деканы Васил Гарифуллин гамәли политология кафедрасында «PR-консалтинг» һәм «Реклама технологияләре» лабораториясен ачу тәкъдиме белән чыкты. Ректоратта катнашучылар әлеге теләкне бер тавыштан кабул итте. Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтында суперкомпьютер модельләштерү лабораториясен ачу мәсьәләсе дә уңай хәл ителде.

Төрлеләр өлешендә беренче булып, 30 июньгә кадәр булган килешүнең вакыты төгәлләнеп килү сәбәпле, КФУ студентларын Универсиада авылыннан чыгару соравы каралды. Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор Ариф Межведилов сүзләренә караганда, җәйге практика үтү чорында гына студентлар тулай торакларда яшәп тора алачак.

Ариф Межведилов ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитеты Яшьләр моделе утырышы турында да мәгълүмат җиткерде. Чаралар 4 июльдә КФУ базасында узачак.

Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бәйләнешләр институтында гарәп телләре кафедрасын – гарәп филологиясе кафедрасына, Фундаменталь медицина һәм биология институтының умырткалылар зоологиясе кафедрасын биоресурслар һәм аквакультура кафедрасына үзгәртү соравы да каралды.

• • • •

19-23 июнь көннәрендә Балтыйк федераль университетында (Калининград) когнитив фәннәргә багышланган **V ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ**. Конференциянең максаты – танып белү һәм аның эволюциясе, аралашу чарасы буларак тел, кабул итү процессының механизмнарын тикшереп өйрәнә торган фән вәкилләре өчен махсус форум оештыру. Чарада 30 илдән 500дән артык галим катнашты. КФУдан докладлар белән профессор В.Д.Соловьев (Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты), профессор А.О.Прохоров һәм ассистент Л.В.Артищева (Педагогика һәм психология институты), доцент Е.М.Алексеева (Тел институты), фәнни хезмәткәр В.Н.Антипов (Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты) бик уңышлы чыгыш ясады.

• • • •

22 июнь көнне Казан федераль университеты бинасында **«ЛУКОЙЛ» АЧЫК АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕ КАТНАШЫНДА СЕМИНАР-КИҢӘШМӘ ҮТТЕ**. Татарстанга төрле төбәкләрдән шушы өлкә белгечләре җыелды. Мондый төрдәге квалификация күтәрү курслары инде традициягә әйләнеп бара. Бәхәсләшү үзәге итеп нәкъ менә Татарстанның сайлануы очраклы хәл түгел. «Лукойл» оешмасының Татарстанда эшли башлавына быел 20 ел тула. Семинар эшчәнлеге ике көн дәвам итте. Бу вакыт аралыгында оешма белгечләре элемтәләрне тагын да киңәйтү турында сүз алып бардылар, шулай ук алар өчен Казан буйлап экскурсия оештырылды.

• • • •

Россия Фәннәр академиясе, гомуми патология һәм патофизиологиянең фәнни-эзләнү институты КФУның фундаменталь һәм клиник фармакология кафедрасы профессоры **РЕНАД ЖДАНОВНЫ,** фундаменталь медицинага зур өлеш керткәне өчен, **СПЕРАНСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ МЕДАЛЬ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘДЕЛӘР**. Ренад Ибраһим улы Жданов күп еллар дәвамында генетика һәм ДНК эшчәнлегендә липидларның функцияләрен өйрәнү буенча тикшеренүләр алып бара. Аның һәр эзләнүе зур әһәмияткә ия һәм дарулар ясаганда бик еш кулланыла. Галимебезне шушы дәрәҗәле бүләккә лаек булуы белән чын күңелдән котлыйбыз!

**Ахыры 2нче биттә.**



Диана Поварова фотосы

# Аттестат булды, диплом кирәк!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Башкалабызның уку йортлары шушы көннәрдә кулларына мәктәпне тәмамлау турында аттестат алган укучылар өчен ишекләрен ачып җибәрде. Кабул итү комиссияләре җиң сызганып эшкә кереште.

«Кайсы уку йортына барырга?», «Нинди белгечлекне сайларга?» кебек сорауларга җавапны инде укучылар БДИ тапшырганда ук бирде. Шулай да документ һәм гаризаларны берничә җиргә тапшырып карау дөрес булыр. Яңа уку елында кабул ителгән карар буенча документларны биш уку йортына тапшырырга мөмкин, ә сайланган уку йорты эчендә гаризаларны өч белгечлеккә кадәр кабул итәләр. Узган уку елында КФУ 9 960 гариза кабул иткән. Бүгенге көндә исә бу сан, әле кабул итү кампаниясе башланган гына булуга да карамастан, инде өч меңнән артык.

Университетыбызда быел абитуриентларны кабул итү буенча үзгәрешләр шактый. КФУ ның кабул итү комиссиясе сәркатибе Сергей Ионенко сүзләренә караганда, уку йортыбыз быел беренче тапкыр, ТДГПУ, КДФИИ, КДИИИ белән берләшкәннән соң, тулы бер зур структура буларак абитуриентларны кабул итәчәк. Билгеле булганча, яңа зур университет нигезендә 18 институт һәм факультет оешты. Нәтиҗәдә әзерлек тәртипләренә дә шактый гына үзгәрешләр кертелде. Мисал өчен, быелгы уку елыннан контракт буенча уку бүлекләрендә түләүне, аның суммасын билгеләү яңа технология кысаларында башкарылачак. Бу РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының яңа финанслау нормативларын кабул итү белән бәйле.

Институт, факультетлардагы конкурс, башка еллардагы кебек үк, бик зур. Кабул итү комиссиясе әгъзалары быел бигрәк тә IT-технологияләр (фундаменталь информатика, гамәли информатика, мәгълүмати технологияләр), Бутлеров исемендәге Химия институты, бизнес-информатика бүлекләрендә конкурсның югары булуы турында әйтәләр. Елдагыча, икътисад, юриспруденция белән бәйле белгечлекләргә дә гариза тапшыручылар күп.

Университетның укучыларны БДИга әзерли торган укыту-методик үзәге – Татарстанда мәктәп укучылары белән эшли торган иң зур үзәк. Укыту көндез, кич яисә интернет аша алып барыла. Быел анда 500 гә якын укучы әзерләнгән. Әйтергә кирәк, нәтиҗәләр яхшы – һәммәсенең дә БДИда җыйган баллары югары.

Кабул итү комиссиясендә, чын мәгънәсендә, эш гөрли. Документлар тапшырырга килгән кайбер укучылар белән мин дә сөйләшеп алдым. Алинә Лотфуллина: «Мин документларымны Фундаменталь медицина һәм биология институтына бирдем. Балларым түбән түгел, шуңа күрә башка уку йортына да биреп карыйм әле», – дип фикерләре белән уртаклашты. Ринат Әхмәдуллин: «Гаризамны Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтына бирдем. Конкурс бик зур булмаса гына ярар иде инде», – дип борчыла.

Университетыбыз абитуриентларга бик зур мөмкинлекләр, яңа ишекләр ача, шуңа күрә барысы да сезнең кулда. Шул ишекләрне ачар өчен, күп белем кирәклеген дә онытмасак иде.

## • Фән дөньясында

# «Русча да яхшы бел!»

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

27-30 июнь көннәрендә Филология һәм сәнгать институтында Халыкара «Төрки телләр дөньясында рус теле һәм әдәбияты: заманча концепцияләр һәм технологияләр» дип аталган фәнни-гамәли конференция уза.

Мондый масштаблы чара КФУда беренче тапкыр үткәрелә. Конференция халыкара дәрәҗәсе, темаларның актуальлеге, катнашучыларның киң географиясе белән аерылып тора. Азәрбайҗан, Венгрия, Германия, Италия, Казахстан, Кыргызстан һ.б. илләрдән 250 галим катнаша.

Конференция кысаларында рус телен милләтара аралашу теле буларак функциональләштерү, чит тел буларак укыту кебек проблемалар «түгәрәк өстәл» һәм семинарлар барышында күтәреләчәк.

**Ахыры 2нче биттә.**



Руслан Гыйниятов фотосы

## • Ике авыз сүз

**2 ИЮЛЬ КӨННЕ** «Корстон» күңел ачу үзәгендә Казанда узачак **XXVII ҖӘЙГЕ УНИВЕРСИАДА ЛИЦЕНЗИЯЛЕ ПРОДУКЦИЯСЕНЕҢ ПРЕЗЕНТАЦИЯСЕ БУЛАЧАК**. Хәзерге вакытта Универсиада-2013 рәсми лицензиатлары булып 20 дән артык компания сайланган. Әлеге программа лицензияле товарларны югары сыйфатлы һәм арзан бәядән әзерләүне күздә тота. Журналистларның аккредитациясе *n.narykova@kazan2013.com* адресы яисә 8 9272 46 51 44 (Нина Нарыкова) телефоны буенча 1 июль 15.00 сәгатькә кадәр дәвам итәчәк.

• • • •

26 июнь көнне Яр Чаллы филиалында **IT-ПАРК ҺӘМ КФУ**ның **МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ СИСТЕМАЛАР ЮГАРЫ МӘКТӘБЕНЕҢ ПРЕЗЕНТАЦИЯСЕ УЗДЫ**. Булачак студентларны IT-парк эшчәнлеге белән таныштырдылар. Шулай ук филиал базасында әлеге юнәлеш буенча махсус факультет, 26 нчы гимназиядә махсус сыйныфлар ачарга планлаштыралар. Быелның август аенда Автошәһәрдә ТРда икенче өч үзәктән торган IT-парк эшли башлаячак. Шулай ук абитуриентлар игътибарына «Иннополис Казан» проекты турында да мәгълүмат җиткерелде.

• • • •

Яр Чаллы филиалы яңа уку елына **«ГАМӘЛИ ИНФОРМАТИКА» ЮНӘЛЕШЕ БУЕНЧА ДА АБИТУРИЕНТЛАР КАБУЛ ИТӘЧӘК**. Мондый белгечлекне ачу программалаштыру белән тәэмин итәрдәй югары квалификацияле эшчеләр җитмәү белән аңлатыла. Документлар көндезге бүлеккә генә кабул ителә. Әлеге юнәлеш буенча укырга керергә теләүчеләр өчен информатика, математика һәм рус теленнән БДИ нәтиҗәләре булу мөһим.

• • • •

Россиянең фундаменталь тикшеренүләр фонды яшь галимнәр тарафыннан башкарыла торган **ФӘННИ ПРОЕКТЛАР** (Минем беренче грант) **КОНКУРСЫН АЧЫП ҖИБӘРДЕ**. Барлык конкурслар буенча да тулырак мәгълүматны Фонд һәм КФУ сайтында табарга мөмкин. Гаризалар 1 августтан башлап 15 сентябрьгә кадәр кабул ителәчәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

## • Фән дөньясында

**Башы 1нче биттә.**

Германиянең Славистика университеты доценты, Казан университетын тәмамлаган галимә Х.Вапенханс сүзләренә караганда, немецлар рус телен икенче тел буларак өйрәнә. «Россиянең бик яхшы партнер икәнен аңлаган ата-аналар баласының бөек рус телен, аның фәнни традицияләрен камил белүен тели. Яшьләр исә русчаны бик яратып өйрәнә», – ди галимә.

Үзбәкстанның Дөнья телләре дәүләт университеты профессоры М.Джусумбов фикеренчә, рус телендә күбрәк төрки телле милләтләр аралаша. Үзбәкстан, Казахстан, Каракалпак җөмһүриятләрендә рус теле рәсми рәвештә укытыла, ләкин уку-укыту программалары тиешле таләпләргә туры килми. Мондый проблемалар конференция барышында уңай якка хәл ителер дип ышанабыз.

## • Галимнәребез

# Фәндәге якты йолдыз

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче



Уку йортыбыздагы династияләр белән таныштыруны дәвам итәбез. Аның башында торучы галим Хәбибуллин Шәүкәт Таип улы астрономиянең төрле өлкәләрендә дан казанган. Күп еллар дәвамында Казан университетында астрономия кафедрасы мөдире, физика факультеты деканы һәм фәнни эшләр буенча проректор булып эшләгән.





Шәүкәт аганың әтисе үз чорында йон эшкәртү буенча таныла. Шәүкәт ага – гаиләдә беренче бала, аның җаваплы, ярдәмчел булуы да шуннан килгәндер. Беренче алган белемнәре химия өлкәсенә бәйле була, Казахстанда геологик экспедицияләрдә катнаша, ләкин ул галактикадагы серле дөньяны ачарга тели. 1934 елда Казанга рабфакка керү өчен килә, алга таба укуын университетның астрономия бүлегендә дәвам итәргә тели һәм максатларын тормышка ашыра. Студент вакытта ук фәнни эш белән шөгыльләнә һәм элек билгеле булмаган 7 йолдызны ача! Укуын тәмамлагач, аны аспирантурага чакыралар. Ләкин сугыш бу планнарны җимерә. Әлеге авыр чорда да ул сынмый-сыгылмый, көчле көрәшче булып кала: кече лейтенанттан майор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Физика һәм математика буенча булган төпле белемнәре аны берничә тапкыр канкойгыч сугышта үлемнән саклап кала. Аны хәтта хәрби академиягә чакыралар, астрономиягә бөтен җаны-тәне белән гашыйк яшь галим бу тәкъдимнән баш тарта. Сугыш тәмамланып, бер ел үткәч кенә туган якларына кайткан Шәүкәт әфәнде ике ел эчендә барлык югалткан вакытларны кире кайтара, фәндә яңа үсешләргә ирешә. Аның бертуганнары да шулай ук үзләрен фәнгә багышлаганнар. Шамил әфәнде – икътисад фәннәре кандидаты, ә Хәсән абыйсы – тарих фәннәре кандидаты. Апасы Зөһрә гомере буе югары уку йортында химия фәне укыткан.

Булачак тормыш иптәше белән дә Шәүкәт Таипович университетта таныша. Сөйгәне химия факультетында укый торган була. Бераздан алар бергә шәһәр янындагы астрономия обсерваториясенә укырга китәләр. Бу миниатюр кыз һәрвакыт аның терәге, юлдашы була.

Шәүкәт аганың балалары Гүзәл һәм Илдарның истәлекләренә караганда, әтиләре иртән үк эшкә китә, ә өйгә бик соң кайта. Кайтканда һәрвакыт күчтәнәчләрен дә онытмый. Эшенең никадәр тыгыз булуына карамастан, Шәүкәт ага балаларына вакытын беркайчан да кызганмый. Аларны фотога төшерергә, шахмат уйнарга өйрәтә. Хәтта велосипед алуларын үтенгәч, ул бер ел буе шуның өчен акча җыя. Әти кеше кырыс та була белгән. Аның бер карашы теләсә кайсы ситуацияне уңай якка хәл иткән. Университетта да ул компаниянең җаны була. Һәрчак ярдәмчел, үткер сүзле, акыллы фикерле.

Балалары да әтиләре юлыннан китә. Улы Илдар – физика-математика фәннәре кандидаты, программалаштыру буенча белгеч. Ә кызы Гүзәл (аның паспортында астрономия лабораториясендә туган, дип язылган) – психология фәннәре кандидаты, гомуми психология кафедрасы доценты.

Шәүкәт аганың бөтен хезмәте киләчәк буынга кыйммәтле хәзинә буларак кадерле, астрономия өлкәсендәге эшчәнлеге зур әһәмияткә ия.

*Материал Татарстан Фәннәр академиясе ярдәме белән эшләнде.*

## • Абитуриент колагына

# Һөнәр күккә җиткерер...

**Гөлинә ГАЙНУЛЛИНА,**
Механика һәм математика институты студенты

Бу җиһанда һәркемнең үз сукмагы, үз язмышы. Кемнәрдер сукмакны кемдер кушуы буенча сайласа, кайберәүләр күңел авазын тыңлый. Җәмгыятьтә тотачак урыныбызны да шул сукмак билгели. Менә бу урында сукмакта безнең белән янәшә атлап барачак «һөнәр» сүзен искәртү мөһим. Халык телендә дә әнә бит һөнәр турында нинди мәкальләр яши: «Акыл күпкә җиткерер, һөнәр күккә җиткерер», «Һөнәрле булу гәүһәрле булудан мең артык». Әйе, бик мәгънәле сүзләр. Шуңа нинди дә булса һөнәр сайлаганчы, үзебезне тыңлап карасак иде. Киңәш бирүчеләр күп булыр – күңелең якын, йөрәгең кабул иткәнне сайларга кирәк.

Интернетта язылган мәгълүматларга ышансак, хәзерге яшьләрнең бары 48% үз белгечлеге буенча эшли. Нилектән соң бу? Тәрбиянең җитеп бетмәвеме, киңәшләрнең артык күп булуымы, әллә инде хөкүмәтнең игътибарсызлыгымы? Яшьләрнең дә төрлесе бар. Күбесенең уенда тиз генә баеп китү, эшкә урнашуга, уч тутырып акча алу. Кызганыч. Һәм бу очракта яшьләр гаепле килеп чыга. Ләкин аларны гына гаепләсәк, ялгыш булыр. Әйтик, мәсәлән, укытучы хезмәтен алыйк (үзем шушы юлда булганга күрә, әлеге һөнәр ияләре белән бәйле һәр яңалыкка игътибар бирәм). Елдан-ел аның да дәрәҗәсе арта. Күпьеллык стажы булган белгечләргә генә түгел, яңа гына укыта башлаган яшьләргә дә хөкүмәт ягыннан игътибар зурая. Яңа гына эшкә килүчеләргә йорт, фатир бирү, ниндидер грантка ия булу – болар барысы да шуны раслый. Тик менә хезмәт хакы дигән өлкә бар. Дөрес, авыл, район җирендә укыткан, берничә еллык стажы булганнарга зыянлы түгел, тормыш алып барырга була әле. Ә яшь белгечкә нишләргә? Яшь укытучылар 2-3 ай эшли дә башка эш эзли.

Сайлаган һөнәрең буенча кимендә өч ел эшләргә дип тә куелса, зыянга булмас, минемчә. Монысы инде алдын-артын карамый, җаны теләмәгән, кемдер кушуы буенча укырга керүчеләр өчен уйланырга этәргеч булыр иде. Ни булса да, киләчәк бит без – яшьләр кулында. Без җәмгыятьне үстерергә, алга этәрергә тиеш. Шуңа күрә һөнәрне алдан кат-кат уйлап сайлыйк.

# Студентлар «авылда» яши



2009 елның июнендә төзелә башлаган Универсиада авылы бүген инде гөрләп яши. 2013 елгы Универсиадага кадәр һәм аннан соң да студентлар яшәсен өчен төзелгән бу биләмә чынлап та студентлар авылын хәтерләтә.

Универсиада авылында барлыгы 7 мең студент яшәрлек урын бар. Быел укырга керергә җыенган абитуриентларның да монда урнашырга мөмкинлекләре бар дигән сүз. Һаман саен «авыл», «авыл», дип сөйләшсәк тә, Универсиада авылы гади авыл гына түгел. Моны инде биредә яшәп караган студентлар бигрәк тә белә. Бүлмәләрдә яңа, заманча җиһазлар, тәртип, чисталык, гомумән, студентларга уку өчен яхшы шартлар тудырылган. Инде шуңа да ахры, җәйге ялларга таралышканда, күпләрнең йөзләрендә моңсулык чагылып үтте.

Студентлар өчен тулай торак дип исәпләнелсә дә, бик күп еллар элек төзелгән тулай торaклардан нык аерыла шул бу. Пушкин, Кызыл Позиция, Гадел Кутуй, Бутлеров урамнарында урнашкан тулай тораклар да Универсиада авылыннан калышмый. Шулай да «авыл»да яшәве рәхәтрәк. Бүлмәләрдә нибары 2-3 кеше яши. Бүлмә саен душ бар. Аш бүлмәсе 3-4 бүлмәгә бер. Кондиционер, Интернетка керү өчен мөмкинлекләр каралган. Куркынычсызлык өчен дә борчылыр урын юк: коридорлар видеокамера белән тәэмин ителгән. Тулай торак билгеле бер вакытта бикләнә. 11 дән 6 га кадәр шаулап йөрү юк.

Универсиада авылында 24 сәгать буе эшли торган даруханә бар, кибетләр якын (киләчәктә ишегалдында да кибет ачарга ниятлиләр), бассейнга, тренажёр залларга йөрү, тимер аякта шуу (ишегалдында) кебек мөмкинлекләр каралган. Ә җәй көне велосипедта, роликларда йөрергә (кулланып торырга бирәләр), теннис, футбол уйнарга була. Һәр бәйрәм саен төрле кичәләр, психолог белән очрашулар, дискотекалар үткәрәләр, кунаклар еш килә.

Студент еллары – хатирәләргә бай чор! Әгәр дә бу елларны студентлар тулай торагында, бигрәк тә Универсиада авылында үткәрергә туры килсә, син икеләтә бәхетле дигән сүз! КФУга ашык, юкса «авыл»да бүлмәсез калуың бар!

● Телләр белгән - илләр гизгән

# Ихлас һөнәр ияләре

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче



Җир шарында 6 меңнән артык тел барлыгы билгеле. Берсендә миллионлаган кеше сөйләшсә, икенчесен ун кеше дә аңламаска мөмкин. Беренчеләре, кагыйдә буенча, бай әдәби тарихка да ия. Югары белемле филолог-белгечләрне бүгенге көндә Казанда бердәнбер уку йортында – Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында әзерлиләр. Институт директоры, профессор Рәдиф Җамалетдиновка яңа уку елына кабул итү кампаниясе башланган көннәрдә без дә мөрәҗәгать иттек.

**- Филология һәм сәнгать институты – КФУда иң зур институтларның берсе. Биредә 4 меңнән артык студент белем ала. Әлеге саннар артына нәрсә яшерелгән икән?**

- Студентларыбыз бакалавриат, белгечлек һәм магистратура буенча төп 12 белем бирүче программа буенча укый. Программалар 39 төрле укыту профилен үз эченә ала. Алар өч зур төркемгә бүленә: гуманитар фәннәр, мәгариф һәм педагогика, мәдәният һәм сәнгать.

Институтның өч бүлеге исемендә «филология» сүзе кулланыла – рус, татар һәм роман-герман филологиясе. Дүртенчесе әлеге өч бүлекне берләштерә, гомумиләштерә, бу – тәрҗемә һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге. Һәркайсында төрле дәрәҗәдә татар, рус һәм инглиз телләре өйрәнелә. Бишенчесе – сәнгать бүлеге – мәгариф, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә җәмгыять алдындагы бурычыбызны өлешчә үтәргә ярдәм итә.

**- Белгечләрнең җәмгыятьтәге роле, аларның әһәмияте турында да кыскача әйтеп узсагыз иде?**

- Республикабызда гына түгел, аннан тыш төбәкләрдә дә татар, инглиз һәм милләтара аралашу теле булган рус телен камил белүче белгечләр һәрвакыт кирәк. Безнең уку-укыту программалары халкыбызның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен дә, филология һәм сәнгать өлкәләрендә заманча фәнни-тикшеренү эшләрен дә тиешле югарылыкта алып барырга өйрәтүгә юнәлтелгән. Бакалаврлар укуларын магистратурада, киләчәктә аспирантурада дәвам итәргә мөмкин. Һәр студент университетыбызның бик бай китапханәсендә шөгыльләнә ала, интернетка чыгу мөмкинлеге дә тулысынча тәэмин ителгән.

**- Бүгенге көндә югары белем алуның, аеруча бюджет хисабына, төп проблемасы: белгечлек алып чыккан студентлар берничә ел дәвамында әзерләнгән, үзләре сайлаган юнәлеш буенча эшләми. Моны ничек аңлатасыз?**

- Мондый проблема дөрестән дә бар. Ул безнең университет өчен генә актуаль түгел. Укырга кергәндә, укучылар киләчәк һөнәрләрен төгәл аңлап бетерми яисә, диплом алгач, «хезмәт хакының аз икәнен» ачыклыйлар да башка эшкә урнашалар. Кызлар кияүгә чыгып, тормыш иптәшләре янына күчеп китәләр. Бигрәк тә хәрбиләргә илнең төрле почмакларында эшләргә туры килә. Еш кына шундый очраклар да була: вузны тәмамлагач, яшь белгеч башка өлкәдә (алган һөнәре буенча түгел) эшли, ләкин күпмедер вакыттан соң, үз белгечлеге буенча эшкә урнаша, уңышлы гына эшләп китә.

**- Ни өчен вузга килүче укучылар һөнәр турында аз мәгълүматлы була? Бу проблеманы ничек хәл итәргә?**

- Бөтен вузлар һәм һөнәрләр өчен җавап бирә алмыйм. Филологиягә килгәндә, ул борынгы фән. Бүген күзгә күренеп яңара, ләкин күпләр моны әле белеп бетерми. Безнең программалар фундаменталь һәм гамәли филология буенча заманча күзаллау булсын өчен генә түгел, ә реаль тормышта куллана алырлык итеп төзелгән.

Абитуриентлар, булачак һөнәрләре турында тулырак мәгълүмат алсыннар, бездәге юнәлешләр буенча булган белемнәрен арттырсыннар өчен, институтыбыз каршында Кече филология һәм сәнгать институты ачтык.

**- Институтта чит телләр укытылуның торышы турында тулырак мәгълүмат бирсәгез иде.**

- Роман-герман бүлегендә студентлар инглиз, француз, немец, испан телләрен өйрәнә. Моннан тыш, институтта берничә ел инде Кембридж университетының Имтихан үзәге эшли. Кембридж университеты сертификатының срогы чикләнмәгән һәм ул бөтен илләрдә таныла. Укуын киләчәктә дәвам итүче студентлар яисә чит илдә эшләргә җыенганнар өчен сертификат зур ярдәмгә килергә мөмкин.

Гомумән, бүген институтыбыз гуманитар юнәлешне сайлаган яшьләргә үз максатларына ирешү өчен, барлык мөмкинлекләрне тудыра. Институтның һәр бүлегендә инглиз телен тирәнтен өйрәнү өчен тиешле шартлар бар. Белгечлек буларак, ул дипломга да языла.

**- Мәгълүмати технологияләр заманы дигән сүзләр инде баналь яңгырый. Шулай да компьютер яшьләр арасында бик популяр һәм алга киткәнне аңлата. Югары сыйныф укучылары исеменнән сорау: филолог һәм компьютер ни дәрәҗәдә бәйләнгән?**

- Югары уку йортын тәмамлаган филолог – ул күпкырлы, югары квалификацияле, алай гына да түгел, лингвистика һәм заманча мәгълүмати технологияләр өлкәсендә яхшы хезмәт хакы алып эшли торган белгеч. Ә җәмгыятьтә мәгълүмат һәр секунд, минут саен артып, үзгәреп тора. Заманча технологияләр текстларны анализлау өчен яңа мөмкинлекләр ача. Филологлар санау техникасын XX гасыр урталарында куллана башлый, ул заман өчен аларны эксперимент буларак карарга кирәк. Бүгенге көндә без заманча җиһазлардан файдаланабыз.

Боларны истә тотып, үзебезнең институтта, аның татар филологиясе бүлегендә махсус «филологиядә мәгълүмати технологияләр» дип исемләнгән кафедра ачтык. Быел әлеге бүлекнең I курсына татар теле һәм әдәбияты, мәгълүмати технологияләр дигән профильгә студентлар да кабул итәчәкбез.

**- Әңгәмәбезне төгәлләр алдыннан, яшьләргә нинди теләкләр җиткерер идегез?**

- Безнең укытучыларыбыз, аспирант һәм студентларыбыз ел дәвамында мәктәп һәм урта һөнәри белем бирү уку йортлары укучылары, мөгаллимнәре белән төрле тематика буенча күп чараларда катнашып, очрашып торды. Институт, университет тормышы, мондагы яңалыклар буенча без турыдан-туры да, интернет челтәре аша да аралаштык.

Гомумән, илебезнең бай тарихлы һәм бүгенге көндә иң алдынгы 10 уку йорты исемлегендәге Казан федераль университетының башка уку йортларыннан аерып торучы өстенлекле яклары бихисап. Миңа калса, абитуриентларга, әти-әниләргә, Казанга килеп, бу уку йорты белән якыннанрак танышырга кирәк. Читтән килеп укучыларны замана таләпләренә җавап бирә торган яшәү шартлары белән (Универсиада авылы) тәэмин итәбез. Бу шулай ук безнең зур өстенлегебез булып тора. Без үз милләтенә ихлас хезмәт итәргә теләүче, креатив фикер йөртүче, яхшы әзерлекле абитуриентларны көтеп калабыз!

**Татар филологиясе бүлеге мөдиренең тәрбия эшләре буенча урынбасары Дамир Хөснетдинов:**

«Быел төп өч белгечлек буенча кабул итәбез: татар теле, әдәбияты һәм инглиз теле; татар теле, әдәбияты һәм мәктәпкәчә белем бирү; филология һәм мәгълүмати технологияләр. Татар филологиясе бүлеген тәмамлаучылар өчен укып бетергәннән соң, укытучылык һөнәреннән тыш, бик күп мөмкинлекләр ачыла. Аларны бары тик дөрес куллана гына белергә кирәк. Мисал өчен, уку дәвамында төрле конкурсларда, бәйгеләрдә җырлап, сәләтеңне үстереп килсәң, диплом белән беррәттән «җырчы» дигән исемне дә алып чыгуың бик мөмкин. Кайчандыр Илназ Баh, ИлГәрәйләр нәкъ менә шушы факультет студентлары иде. Бүгенге көндә алар татар эстрадасының якты йолдызларына әверелде.

Иҗат белән дус яшьләр «Илһам», «Әллүки» иҗат берләшмәләрендә тәҗрибә туплый ала. Вакытында үз-үзен күрсәтә белгән студентларны, укып бетергәч, төрле нәшриятлар, газета-журналлар эләктереп алырга гына тора. Рүзәл Мөхәммәтшин дигән студентыбыз бүгенге көндә «Идел» яшьләр журналында мөхәррир, Динара Әхмәтова исә университетыбызның «Дарелфөнүн» газетасында алыштыргысыз хәбәрче булып эшли. Һөнәри язучыларыбыз, драматургларыбызның да күпчелеге татар филологиясе факультеты студентлары. Ленар Шәех, Эльвира Һадиева, Резедә Гобәева һ.б. бу юнәлештә аеруча уңышларга иреште. Шул исәптән телевидение-радиода, конгресста, спорт, театр өлкәсендә дә исемнәре билгеле студентларыбыз шактый. Иң мөһиме: теләп укырга кирәк!»

**Роман-герман филологиясе бүлеге мөдиренең фәнни эшләр буенча урынбасары Надежда Титова:**

«Безнең бүлектә өч белгечлек бар. Укытучылык юнәлеше буенча: инглиз теле һәм өстәмә икенче чит тел; филология буенча: инглиз теле һәм әдәбияты, испан теле һәм әдәбияты белгечләре әзерләнә. Беренче чиратта, бүлекне тәмамлаучылар үз юлларын төрле мәктәпләрдә таба. Хәзерге заманда чит телне камил белү эшкә урнашканда аерым бер таләп буларак бара. Шуңа күрә Президент аппаратында да инглиз, испан һәм башка чит телләрне яхшы дәрәҗәдә белүчеләрне чакырып кына торалар. Бүлегебзнең иң зур плюсы – халыкара Кембридж системасы буенча эшли торган имтиханнарны бирү. Ә Кембридж имтиханнарын бирүчеләр теләсә-кайсы чит илгә укырга, эшләргә китә алалар. Укып бетергәннән соң, эш таба алмыйча йөргән студентлар роман-герман филологиясе бүлеге өчен, гомумән, ят күренеш».



**Рус филологиясе бүлеге мөдире Резедә Мөхәммәтшина:**

«Рус филологиясе бүлеге студентлары киләчәктә төрле типтагы мәгариф оешмаларында эшләү өчен, филологик, фәнни-тикшеренү, укыту-гамәли һәм психологик-педагогик әзерлек алып чыга. Алар үзләрен социаль-гуманитар, иҗади, мәдәни-агарту өлкәләрендә реальләштерә, әдәби-мәдәни музейларда, китап нәшриятларында, матбугат - үзәкләрендә яки реклама агентлыкларында эшли алалар. Безнең чыгарылыш студентларына Россия шәһәрләрендә генә түгел, чит илләрдә дә сорау зур. Наталья Смолкина, Любовь Кочнева кебек студентларыбыз бүген мәктәп директорлары дәрәҗәсенә иреште. Равил Сайганов, Николай Токрановны «Эфир», Светлана Родинаны «Россия» телеканалы аша танып беләбез. Язучы һәм сценарист Денис Осокин, шагыйрә Анна Русс та - безнең чыгарылыш студентлары».

**Әлфия Юсупова, тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеге мөдире:** «Безнең бүлектә тәрҗемәчеләр ике юнәлештә әзерләнә. «Филология. Тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме» һәм «Лингвистика. Тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме». Беренче юнәлештә татар теленнән рус теленә һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү серләрен өйрәтәләр. Студентларга зур мөмкинлекләр тудырыла. Җиһазландырылган лингафон кабинетлары, синхрон тәрҗемә класслары, югары дәрәҗәле укытучылар. Алар Дәүләт Советында, Министрлар Кабинетында, газета-журнал редакцияләрендә практика үтә. Бу юнәлешне тәмамлап, тәрҗемәче дипломы алганнан соң, белгечләр әдәби тәрҗемәче, синхрон тәрҗемәче, төрле дәүләт оешмаларында тәрҗемәче булып эшли алалар. Әлбәттә, алар арасыннан киләчәктә безнең бүлекнең укытучылары да чыгар.



«Лингвистика. Тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме» юнәлешендә берничә чит тел белгән тәрҗемәчелер (бүлектә инглиз, алман, француз, итальян, испан телләре өйрәтелә) әзерләнә. Аларга Татарстанда, Россиядә, Көнбатыш Европа илләрендә дә ихтыяж зур. Югары квалификацияле тәрҗемәчеләр һәр җирдә кирәк. Мисал өчен, бүгенге көндә бүлекне тәмамлаган берничә кеше Pricewaterhouse Coopers, Promo Best һәм башка компанияләрдә эшли. 2013 елда үткәрелә торган Универсиадада тәрҗемәче булып эшләргә чакырылган студентларыбыз да бар».

**Зилия Явгильдина, сәнгать бүлеге мөдире:**

«Бүлегебездә студентларның фәнни түгәрәкләре, иҗади-эксперименталь лабораторияләр, компьютер технологияләре үзәге, «Tatar-style» кием дизайн-студиясе, «АРТиФАКТ» факультет гәҗите, музыкаль-педагогик театрлары эшләп килә. Студентларыбыз үзләренең белем алу дәверендә заман таләпләренә туры килә торган, бүгенге көндә күп кенә рәссамнар, дизайнерлар, рекламачылар, полиграфистлар куллана торган барлык график һәм музыкаль-компьютер программаларын да үзләштерәләр, төрле интерьер дизайннары, шәһәр архитектурасы, ландшафт объектлары проектларын төзиләр; заманча тавыш һәм ут эффектларын кулланып спектакльләр, хореографик номерлар куялар. Кайбер педагогик яисә иҗади оешмалар үзләрен яхшы итеп күрсәтергә өлгергән студентларыбызның диплом алганнарын эшлекле тәкъдим белән көтеп тә торалар. Бүлегебез музыкаль сәнгать һәм әдәби белем бирү өлкәсендә дүрт меңнән артык белгеч әзерләгән. Алар арасында фән кандидатлары һәм докторлар, профессорлар һәм доцентлар, композиторлар бар».



**• Җиңүнең 67 еллыгына багышлап**

# Ризык кадере

**Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
Филология һәм сәнгать институтының белем бирү бүлеге җитәкчесе

Зур туй мәҗлесендә утырабыз. Сый-нигъмәттән өстәлләр сыгылып тора. Эчемлекнең нинди төре генә юк! Савыт-сабаның да өстәлгә иң затлысы куелган.

Күрше өстәлдәгеләр үзләре белән дүрт-биш яшьләр чамасындагы улларын ияртеп килгәннәр. Гадәттә, мондый мәҗлесләрдә кечкенә балалар сирәк күренгәли һәм алар, күбесенчә, күзне иркәләп, бәйрәмгә ямь өстәп, биюче абый-апалар янында бөтерелә.

Бу бала гаиләдә бердәнбер, күрәмсең. Үз-үзен тотышы, гадәтләре шуңа ишарәли. Өстәлдәге ризыкларга төртеп күрсәтә-күрсәтә, әле теге, әле бу әйберне сорый. Әнисе алып биргәне ошамый, ризыкны кискен хәрәкәт белән этеп җибәрә, еламсырап һаман нидер аңлата, нидер таптыра. Баланың өзек-өзек сүзләре безгә дә ишетелә: «Йогурт хочу, купи мне йогурт...» – дип, әнисенең күлмәк җиңен тарткалый. Әйтерсең лә, сый-нигъмәттән сыгылып торган өстәл бөтенләй юк.

Билгеле, мондый күренешне соңгы вакытта еш күзәтергә була. Һәркөн кичкырын эштән кайтканда кибеткә керсәң, шундый ук яшь бала җитәкләгән ханымны очратасың. Ул ханым, кибет киштәләренә төртеп әйбер сораган баласына карап, нәрсә алырга кергәнен оныта, ник кергәненә үкенә башлый. Бала белән ана арасындагы диалог гел бертөсле: «Мам, купи мне чупа-чупс, купи мне чипсы!!!» Бу җөмләләр җиңне тарткалау, аяк белән идәнгә тибү кебек хәрәкәтләр белән чиратлаша. Күренешнең ахыры ничек тәмамлануы да һәркемгә мәгълүм.

Бүгенге көн балаларының күбесе шундый: җаны ни тели, шуны таптыра, кулыннан төшеп киткән ризыкны аяк белән читкә тибәрә, аш шулпасыннан кишер, суганын чүпләп тәлинкә читенә этәрә, алдындагы ризыкны ошатмыйча (борын җыерып), өстәл читенә алып куя. Әти-әни баланың бу гадәтләрен гадәти күренеш буларак кабул итә, бер сүз әйтми генә, ашалмаган ризыкны чүп савытына «озата», кибеттән «күңелгә ятышлы» ризыклар ташый. «Ризык кадере» дигән төшенчә телгә дә алынмый, күңелгә дә керми.



Ирексездән, балачагы сугыш елларына туры килгән әти-әниләрнең сөйләгәннәрен искә төшерәм.

1933 елның сентябрь ае. Балык бистәсе районы Күки авылында Хөсәен һәм Хәербанулар гаиләсендә төпчек (сигезенче) бала булып минем әни дөньяга килә. Җиде айлык булып туганлыктан, бик нәни һәм зәгыйфь була ул. Озакламый сугыш башлана. Гаиләдәге ике абыйсы Бөек Ватан сугышына китә һәм кире әйләнеп кайтмый. Игезәкләр дә (Фатыйма белән Исмәгыйль), тагын бер абыйсы Мияссәр дә якты дөнья белән хушлашалар. Озак та үтми, әнисе авырый башлый һәм әнигә 12 яшь тулганда (1945 елда) үлеп китә...

Ул чор кешеләренең кайсын гына тыңласаң да, вакыйгалар бертөсле – сугышка киткән, хәбәрсез югалган ир-егетләр, тол калган хатыннар, төрле авырулардан үлгән балалар, ачъялангач сабыйлар...

Яшьли ятим калу, ачлык-ялангачлык, черек бәрәңгедән яки бәрәңге кабыгыннан пешерелгән ризык, суга изгән умач, алабута күмәче – менә әнинең балачагы. Бер әнинең генә түгел, барлык сугыш елы балаларының балачагы. Әни сөйләгәннәрне бик бирелеп тыңласам да, ул алабута күмәченең, черек бәрәңгенең тәмен укучыга җиткерә алмам, чөнки аны аңлар, аңлатыр өчен шул ризыкларның тәмен татыган сугыш чоры баласы булуың кирәктер, мөгаен.

Шуларны искә алам да тирән уйга калам. Бер караганда, әллә ни күп гомер узмаган. Шул ачлы-туклы тормышта үскән кешеләрнең балалары, оныклары шул чор вакыйгаларын энә күзеннән үткәреп, «ризык кадере» дигән төшенчәне күңеленә беркетергә, алдына килгән ризыкны борын җыермыйча ашап, табын яныннан шөкер итеп китәргә тиеш, югыйсә. Күп әти-әни үзе дә бала алдында бертуктаусыз «Минем ул ризыкка исем дә китми», «Моның тәмсезлеге! Авызга да алырлык түгел!» – дигән сүзләр кабатлый.

Әйтергә теләгән сүзем шул: әти-әниләр өлешне калдырмый ашарга, өстәл яныннан рәхмәт әйтеп китәргә, ризыкның валчыгын коеп, анда-монда ашап йөрмәскә кирәклеген һәрдаим искәртеп торсыннар, үзләре дә бала алдында сөйләме, гадәтләре белән ризыкның бар нәрсәдән олы икәнлеген аңлатсыннар иде. Әти-әни белән беррәттән балаларны радио-телевидение һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары да тәрбияләсә, бер дә артык булмас иде, мөгаен. Билгеле, сугыш чоры, ачлык-ялангачлык, бәхетсез балачак турындагы фильм, язмаларга караганда, «ашагыз, эчегез, моннан тәмле әйбер юк» эчтәлегендәге рекламалар күрсәтү, ишеттерү радио-телевидение өчен файдалы. Әмма сугыш чоры кешеләренең тормышы, сабыйларның балачагы, бер телем икмәккә тилмереп яшәгән көннәре турында һәрдаим (бәйрәм көннәрдә генә түгел) документаль, нәфис фильмнар, тапшырулар күрсәтелсә, язмалар бастырылса, хәзерге буын «хөрмәт», «ризык кадере» дигән олы төшенчәләрне күңеленә ныграк беркетер иде...

**• Табигать хозурында**

# Эх, җиләкле җәйләре...

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче


Быелгы җәй җиләкнең күп булуы белән аерылып тора. Кайсы якка гына кайтма, кайсы авыл кешесе белән генә гәпләшмә, телләрендә бер сүз: «Быел җиләк күп»!



*Ходайның кодрәтедер инде, дөрестән дә, узган ел әллә ни җиләкле булмады.*

*Ә быел исә... Быел ул күп! Уйлап карасаң, нинди нигъмәт, нинди байлык бит ул җир җиләге! Аңа беркем су сипми, чүпләрдән дә арындырмый, ә ул үсә, эре булып, баллы булып. Җиләкнең шифалы яклары да бихисап.*

*Җиләктән кайнатма ясаганда, файдасы күбрәк була, диләр. Бу шикәр сиробында җиләкнең кристаллашуы белән бәйле. Җиләк тәмле, ә җыярга яратабызмы икән соң? Шул хакта без университетыбыз студентлары белән сөйләшеп алдык.*



***Лилия Якупова:** «Әйе быел дөрестән дә җиләкнең эрелегенә, куплегенә шаккатып кайттым! Мин җиләкне үзебезнең Теләче районында җыям. Якыннарым белән күз ачып йомганчы чиләкләребезне тутырдык!»*



***Айгөл Шәрипова:** «Әле сессия бетте генә. Туган якларыма кайтып җитә алган юк. Телефон аша сөйләшкәндә, әнием гел: «Әйдә җиләккә»,— дип кызыктырып тора. Ә үзем әлегә барырга өлгермәдем».*



***Лилия Бәдретдинова:** «Юк, җиләккә барырга насыйп булмады әле. Авылга кайтканчы бетмәсә ярый инде. Җәйнең иң кызган мәлендә музейларда практика үтеп йөрибез».*



***Ләйсән Фәтхетдинова:** «Җиләк быел күп, диләр, әмма барырга һаман өлгерә алмыйм әле. Узган ел сессия сәбәпле җитешмәдем. Быел имтиханнар да иртә бетте, ә туган якларга кайтып җитеп булмый. Җыярга исәп бар, мин кайтканчы җыеп кына бетермәсеннәр иде!»*



***Фирүзә Закирова:** «Җәй кайчан башлана? Ямьле җәй кызарып җир җиләге пешкәч башлана дип уйлыйм мин. Быел, Аллага шөкер, авылга кайтып, үз кулларым белән җир җиләге өзү бәхетенә ирештем. Җиләк җыюның рәхәтен үзе җиләк җыймаган кеше белмидер, мөгаен! Җиләк өлгерде, димәк, чын җәй башланды».*

*Менә шулай, дуслар! Ә сез җиләккә бардыгызмы әле?*

**• Дөнья үзебезнеке**

# Өйдәге эш һәм зур мөмкинлекләр

**Динара Зиннәтова,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

Җәй җитеп, сессияне япкач, студентларның күбесе туган якларына кайтып тарала. Казанда нинди дә булса эштә рәсми рәвештә теркәлгән яшьләргә мондый бәхет тәтеми – зур шәһәр мәшәкатьләре аларны өйләренә ял көннәрендә генә «җибәрә». Ике куянның койрыгын берьюлы тотарга теләгән студентлар интернеттагы эзләү системаларына «работа на дому» сүзтезмәсен кертеп, ашыгыч рәвештә уңайлы эш шартларын карый башлый. Өендә генә утырып акча эшләү бүген реальме? Шушы сорауга җавап табып карыйк.

Әлбәттә, теләсә нинди һөнәр белән мондый уңайлы шартларда шөгыльләнеп булмый. Шуңа күрә «өйдә эшләп була торган» эшчәнлек исемлегенә, беренче чиратта, компьютер һәм программалаштыру белән бәйле һөнәрләрне кертергә кирәк. Бу эшкә алыныр өчен, әлеге өлкәдә җитәрлек белем һәм тәҗрибә булуы зарур.

Интернет челтәрендә бүген зур тизлек белән төрледән-төрле сайтлар үрчи һәм аларның һәрберсен мәгълүмат белән тутырырга кирәк. Сайтларны алга чыгару белән шөгыльләнүче SEO компаниясе бу эш өчен копирайтерларны яллый. Копирайтер – төрле темаларга язмалар булдыручы кеше. Монда эшләү өчен рус телендә хатасыз һәм аңлаешлы яза белергә, теманың кызыклы якларын аерып күрсәтергә кирәк. Ә иң мөһиме, копирайтинг белән өеңнән чыкмыйча, теләсә нинди шәһәрдә торып та шөгыльләнергә була. Журналистика, филология бүлекләрендә белем алучы яшьләр өчен бу – бик шәп вариант.

Югары дәрәҗәдә нинди дә булса чит телне белүчеләр өчен дә өйдә эшләү буенча ишекләр ачык: глобализация чорында тәрҗемәче хезмәте бик югары бәяләнә.

Санап киткән һөнәрләр – зур исемлекнең бер өлеше генә. Безнең заманда теләсә нәрсәне табып була – эзли белергә генә кирәк. Шуңа күрә, энтузиазм белән тулып, үзеңә тулысынча туры килгән, уңайлы шартлар тәкъдим иткән эшне табу кыен түгел. Мөмкин булмаган нәрсә юк!

**• Сәламәтлек**

# Колак ишетсен дисәң...

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Спорт белән шөгыльләнгәндә я тыныч кына урамда барганда, һәр өч кешенең берсен колак «аппаратлары» (колакчын) белән күрергә була.

Күп очракта алар тынычландыра торган талгын музыкага түгел, ә колакларны ярып чыгардай «доңгыр-доңгыр»га игътибар бирәләр. Әлбәттә, болай тыңлаганда, колакларга тиешле тавыш катылыгы 85 децибелдән артып китә.

Мондый моданың килеп керү сәбәбе нидә соң? Кешеләр башкаларның тавышыннан, әйләнә-тирә шаукымыннан качарга тырышып, үз дөньяларына чумарга телиләр. Каты яңгырап торган музыка барганда, бу, дөрестән дә, шулай тоела. Музыка һәм шуның көенә син барасың! Әмма болай эшләүнең тавыш ярыларына никадәр зыянлы булуын күпләребез аңлап та бетерми.

Галимнәр тикшеренүләренә караганда, хәтта даими рәвештә шушы үлчәмдә генә музыка тыңлау да, киләчәктә саңгыраулыкка илтергә мөмкин. Элек, гомумән, андый аппаратлар булмаган, шуңа карамастан колак ишетмәүдән зарланучылар байтак. Уйлап карагыз: бер унбиш-егерме елдан аларның саны күпмегә җитәр икән?!



Әз генә сәламәтлегебезне кайгыртсак, без өйгә кайтканчы булса да колак «аппаратлары»ннан баш тартыр идек. Ә өйдә яраткан радиобызның яисә яраткан җырларыбызның моңнарын да талгын гына иттереп тыңларга була, тик сәламәтлегебезгә зыян салмыйча – колакчыннардан башка гына...




DARELFONYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.